КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 июнь

г.Казань

№ 472

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү тәртибен һәм программасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 878 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү тәртибен һәм программасын раслау турында» 2012 ел, 20 октябрь, 878 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 май, 320 нче карары, 2020 ел, 08 май, 371 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасын раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 һәм 146 статьялары, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасын расларга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин